КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 апрель г.Казань № 349

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче, 2020 ел, 27 март, 223 нче, 2020 ел, 30 март, 234 нче, 2020 ел, 31 март, 240 нчы, 2020 ел, 03 апрель, 252 нче, 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 10 апрель, 272 нче, 2020 ел, 13 апрель, 280 нче, 2020 ел, 18 апрель, 306 нчы, 2020 ел, 21 апрель, 313 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктның «а» пунктчасында «турыдан-туры янау очракларыннан тыш,» сүзләреннән соң «шулай ук аларның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә дачага (шәһәр читендәге йортка) бару яки дачадан (шәһәр читендәге йорттан) кайтуга бирелгән махсус рөхсәтләре булган очракта» сүзләрен өстәргә;

11 пунктның икенче абзацында «, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт органнары яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырыла торган, катнашучылар саны 20 кешедән артмаган чараларда гражданнар катнашуы өчен» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$. 2020 елның язгы ау чорында Татарстан Республикасы территориясендә аучылык җир-суларында курыйлы киек кошларга ауны тыярга, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру буенча чаралар

хакында» үзгәрешләр кертү хакында 2020 ел, 31 нче март, 240 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 13 апрель, 279 нчы, 2020 ел, 18 апрель, 306 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) ачык һавада физик культура һәм спорт белән индивидуаль шөгыльләнү.»;

унөченче абзацта «10 һәм 11 пунктчаларда» сүзләрен «10 – 12 пунктчаларда»сүзләренә алмаштырырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән соң бер көн узгач үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин